СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2019 с. Сарманово № 160

Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр мониторингын үткәрү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Карарга теркәлгән "Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне" расларга.

2. Органам местного самоуправления Сармановского муниципального района Республики Татарстан:

в своей нормотворческой деятельности руководствоваться Положением, утвержденным пунктом 1 настоящего решения;

назначить лиц, ответственных за выполнение указанного Положения;

внести соответствующие изменения в должностные инструкции муниципальных служащих, назначенных ответственными лицами.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

нормалар иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларның законнарга, муниципаль берәмлекләрнең уставларына туры килүен системалы рәвештә контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында мониторинг үткәрүне тәэмин итә торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация